ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№1444 «16» 11 2017 ел

Мамадыш муниципаль районы
Башкарма комитетының 2017 елның
9 гыйнварындагы «2017 елда районның
гомуми белем бирү учреждениеләрендә
укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне
оештыру турында» 3 номерлы карарына
үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслылык һәм мохтаҗлык критерийларын куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 9 гыйнварындагы «2017 елда районның гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны кайнар аш белән тәэмин итүне оештыру турында» 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 6 пунктка түбәндәге эчтәлектәге икенче абзац өстәргә:

«МКУ «Отдел образования» Мамадыш муниципаль районы башкарма комитеты МКУ «Мәгариф бүлегенә» (Габдрахманов И.Н.) әлеге карарда күрсәтелгән гражданнарга социаль ярдәм чаралары турындагы мәгълүматны социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасың (ЕГИССО) файдаланып, ЕГИССО операторы тарафыннан билгеләнгән форматта җиткерүне тәэмин итәргә.

1.2. 7 пунктка түбәндәге эчтәлектәге өченче абзац өстәргә:

««Россия Федерациясенең аерым закон актларына адреслылык һәм мохтаҗлык критерийларын куллану принцибын үтәү бурычыннан чыгып социаль ярдәм чараларын күрсәтүне исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм чаралары күрсәтүче органнар күрсәтелгән социаль ярдәм чараларын Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИССО) куллану юлы белән һәм ЕГИССО операторы билгеләгән форматлар нигезендә бирү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче вазифаларын
башкаручы Р.К.Мөхәммәтҗанов